РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Чалпинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге
башкарма комитеты

ул. Центральная, д.39, с. Чалпы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46,
факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

Үзәк урам, 39, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46,
факс (8-5592)35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 апреля 2023 г. № 8

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 13 ноябрендәге 19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә үзгәреш кертү турында (2018 елның 07 маендагы 9 номерлы, 2019 елның 03 апрелендәге 48 номерлы, 2019 елның 18 октябрендәге 73 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьяның 2 пунктының икенче абзацы үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 13 ноябрендәге 19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә (2018 елның 07 маендагы 9 номерлы, 2019 елның 03 апрелендәге 48 номерлы, 2019 елның 18 октябрендәге 73 номерлы карарлар редакциясендә) 2.14 пунктында «бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «үндүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo. tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык: А.М.Мөхәмәтшин